**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күәм авыл җирлеге Күәм торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"24" ноябрь 2023 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Күәм торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Күәм авылы территориясендә 2024 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Күәм торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән,көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, РФ Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрби хезмәткәрләр, аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:
   - бензин белән эшли торган кар чистарткыч сатып алу;
   - төзелеш материаллары сатып алу, Күәм авылы урам юлларын ремонтлау һәм төзекләндерү буенча хезмәтләр өчен түләү;
   - Күәм авылы территориясен чистарту (агач һәм куаклар кисү), эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
   - Күәм авылы зиратлары территориясен чистарту (агач һәм куаклар кисү), эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Күәм авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Күәм авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күәм авыл җирлеге башлыгы Хасбиуллин И.И.